ГЛАВА МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

**Карар** **Постановление**

№ 035 от «25» 02 2021 г.

Муниципаль район башлыгының 2018 елның 2 ноябрендәге 134 номерлы карары белән расланган Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә оешмалар һәм медик-социаль экспертиза федераль учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 21 июнендәге 55-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә, социаль хезмәтләр күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында КАРАР БИРӘМ:

1. Муниципаль район башлыгының 2018 елның 2 ноябрендәге 134 номерлы карары белән расланган Мәдәният һәм мәгариф өлкәсендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатына бәйсез бәяләү үткәрү буенча Иҗтимагый совет турындагы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

- 5.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Утырыш беркетмәсен Иҗтимагый совет утырышы уздырылган көнне рәис һәм секретарь имза куялар.
- 5.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Тавышлар тигез булган очракта, Рәиснең, Рәис булмаганда - Иҗтимагый совет рәисе урынбасарының тавышы хәлиткеч булып тора.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ адрес буенча бастырып чыгарырга.

000045

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары М. Р. Хуҗаҗановка йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы А.П.Иванов